# МӘКТӘП ДУЛКЫНЫНДА

*Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№5 Декабрь 2023 ел*






**Яңа ел бит ул могҗиза, Яңа ел – тылсым.**
**Яңа елда һәр кылган эш бәхеткә булсын!**
**Карлар белән бергә җанга ак өмет иңсен**
**Яңа елда бар җиһанны тынычлык төрсен!**

Яңа ел белән кадерле дуслар! Яңа ел белән котлаулар кабул итеп алыгыз! Яңа ел бәйрәме матур булып үтсен! Алдагы өр – яңа ел бары бәхет – куанычлар гына алып килсен. Туасы таңнар тыныч булсын. Гомер юлларыбыз шатлык белән тулып торсын. Эшләрегез һәрвакыт уң булсын, гөрләп алга барсын, күңелегездә булган мәрхәмәтлелек нуры җаннарыгызны тагын да ягымлы, матур итсен, ялкынландырып бизәп торсын. Кызыклы очрашулар, бәхетле мизгелләр күп булсын! Йортларыбызга авырулар, хәвеф –хәтәр, бәла – каза килмәсен. Гаиләләребездә бәхет уты һәрвакыт сүнмичә янып торсын!

Хөрмәтле коллегалар, Сезгә алда зурдан зур уңышлар телибез! Сәламәт булып, укучыларга ныклы белем һәм тәрбия бирергә төрле шартлар тусын.

Кадерле укучылар! Сезгә укуыгызда һәм алдагы киләчәк яңа елда “4” һәм “5” билгеләренә генә укуыгызны телибез.

Яңа ел белән, киләсе еллар барыбызга да бәхет һәм тынычлык китерүче еллардан булсын!

**Яңа ел килә, яңа ел**
**Күрсәтсен ул яңа юл!**
**Ак бәхеткә, зур уңышка**
**Яхшылыкка илтсен ул!**



## Яңа елны Россиядә кайчан каршылый башлаганнар?

Россиядә Яңа елны 1 гыйнварда каршылау беренче тапкыр 1700 елда кертелә. Ә аңарчы Яңа елны 1 нче сентябрьда каршылаганнар. Яңа ел төнендә салютлар аттыруны, чаналар шууны, Яңа ел алдыннар өйләрне һәм капкаларны нарат ботаклары белән бизәүне Петр I уйлап таба. Ә менә ёлка бизәү XVIII гасырда Австриядә, XIX гасыр башында Франция, Чехия, Венгрия илләрендә, Россиядә XIX гасыр уртасында гына кереп китә. Шул ук вакытта диярлек Яңа елның төп персонажы да кертелә. Бали утравында елына 210 көн туры килгәнлектән, Яңа елны бик еш каршылыйлар.

Яңа ел төнендә Шотландиядә һәр өйнең ишеге ачык, кем теләсә шул кунак булып чыга ала. Кубинлылар Яңа ел төнендә җиргә кувшиннан су коялар, киләсе елның шул су кебек чиста, якты булуын телиләр..Румыниядә пирогларга акчалар, йөзекләр тезәләр, йөзек эләккән кеше иң бәхетле булып санала. Испанлылар Яңа ел белән котлап виноград бүләк итәләр.Италиядә барлык иске киемнәрне чыгарып аталар.

Һәр илнең, һәр гаиләнең үзенең традициясе бар. Безнең мәктәптә дә бик күп еллар дәвамында Яңа елга багышланган төрле бәйгеләр үтә: Кыш бабайны каршылау, кабинетларны бизәү, кардан кар сыннары ясау, күңелле итеп бәйрәм үткәрү, җырлар җырлау, биюләр һәм төрле оригиналь номерлар башкару.

Һәр сыйныф укучылары һәм эти – әниләре ярдәме белән кабинетлар бик матур һәм зәвыклы итеп бизәлде. Кыш бабай белән кар кызын укучылар җырлап, биеп, шигырьләр сөйләп каршы алдылар. Кыш бабай аларга бүләкләр алып килгән иде. Укучыларның башкарган номерлары Кыш бабай белән Кар кызына бик ошады.




Кыш бабайның бүләкләре бик тәмле һәм затлы иде. Ул укучыларга теләкләр теләде, яхшы билгеләргә генә укырга дигән киңәшен әйтте. Укучылар аны тагын көтеп калуларын җиткерделәр,ак юллар теләделәр.

Әй, Кыш бабай, Кыш бабай,
Хуш киләсең, уз бире.
Кунак булып килер дип,
Күптән көттек без сине.



## Чаралардан, бәйрәмнәрдән фотомизгелләр




**Кыш бабай һәм Кар кызы безгә кунакка килде. Әлбәттә, без аларны биетми җибәрмәдек.**



**Кабинетларны бизәүдә әти – әниләребез дә бик тырышып булыштылар. Рәхмәт аларга.**

**Карлар ябалак-ябалак,
Көннәр-төннәр яңа, ак!**

Кыш бабай, бабакай
Котыптан ук килгәнсең
Әле егәрле икәнсең
Күзләр генә тимәсен.



**Яңа елны бергә бергә  каршы алыйк дуслар!**



**Яңа елны каршылап төрле бәйгеләрдә катнаштык. “Яңа ел марафоны”, “ Кардан сыннар”, Яңа ел балмаскарадына бик тырышып әзерләндек.**



**“Карлы фантазия” бәйгесендә районкүләмендә 1 урын яуладык**

**Бу яңа ел-иң яңа ел,
Барсыннан да яңарак!**




Узып баручы 2023 ел безгә бик күп уңышлар һәм шатлыклар да алып килде.



Яңа ел бәйрәменә бик яхшылап әзерләндек. Җырлар, биюләр өйрәндек. Төрле уеннар әзерләдек. Бик матур концерт куйдык.



Яңа елның яңа кары безгә
Яңа бәхет нуры өстәсен.
Өстәлләргә — муллык, күңелләргә —
Ихлас теләкләрнең көлтәсен!





Төрле фәннәрдән район олимпиадаларына катнашып, бик күп призлы урыннар яуладык. Республика олимпиада-ларында да призлы урыннар яулау теләге белән янабыз.



Кыш бабайга шигырьләр сөйләдек, ул безгә бүләкләр өләште.



Ап-ак карларга уралып
Син киләсен Яңа ел!
Ак карлардай ак бәхетле,
Булсын безнең яңа юл.





















**Бик күңелле үтте бәйрәм,**
**Безгә инде кирәк ял итәргә.**
**Телибез сезгә яңа елда**
**Тагын да зур үсәргә.**

**Дус булыгыз хезмәт белән,**
**Шатлык китерсен һәркөн.**
**Яңа елда мәрхәмәтле,**
**Бәхетле булсын һәркем.**